| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| **РЕШЕНИЕ**<br>**26.08.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 88** |
|---|---|---|

Зеленодольск шәһәре Советының «Зеленодольск шәһәре территориясендә 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымы ставкалары, түләү тәртибе турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 264 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск шәһәре Советының 2020 елның 18 декабрендәге 13 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, 2013 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск шәһәре Советының «2020 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымы ставкалары, түләү тәртибе турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 264 номерлы карарының 2 пунктындагы дүртенче абзацын (2020 елның 18 декабрендәге 13 номерлы үзгәрешләр белән) яңа редакциядә бәян итәргә:

«- милек хокукында булган һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата, «Зеленодольск» алдынгы социаль-икътисади үсеш территориясендә эшчәнлек башкару турындагы килешү кысаларында, килешү гамәлдә булу срогына резидентлар».

2. Әлеге карар 2021 елның салым чорында җир салымы түләүдән башлап кулланыла.

3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ